МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

---

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

27.09.2022 № 278

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгына килгән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе турында**

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 ел 12 нче май № 16-ЗТР Татарстан Республикасы Законының 21 нче статьясы нигезендә, коррупциягә каршы тору эшен камилләштерү максатларында, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгына (алда - Татарстан Республикасы ГТХМ) килгән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эш тәртибен расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау Татарстан Республикасы ГТХМда коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең җаваплы заты тарафыннан гамәлгә ашырыла;

коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт мәгълүматларының һәм конфиденциаль характердагы белешмәләрнең сакланышы өчен җаваплы.

3. Әлеге боерыкны министр урынбасарларына, Татарстан Республикасы ГТХМ аппаратының структур бүлекчәләре башлыкларына, Татарстан Республикасы ГТХМ территориаль органнары һәм идарәчәлек карамагындагы оешмалар җитәкчеләренә җиткерергә.

4. Биредәге боерыкны үтәү контролен үземә калдырам.

Министр вазыйфаларын башкаручы Т.В. Кәримуллин

27.09.2022 № 278
Татарстан Республикасы
ГТХМ боерыгы белән
расланган

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгына килгән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 ел 12 нче май № 16-ЗРТ Татарстан Республикасы законының 21 нче статьясын үтәү максатында эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгына (алда – Татарстан Республикасы ГТХМ) килгән коррупция һәм янап акча алу фактлары, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кысу, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне бозу, шулай ук хезмәт урыныннан явызларча файдалану билгеләре булган башка гамәлләр турында белешмәләрне үз эченә алган (алда – мөрәҗәгать), Татарстан Республикасы ГТХМда Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алда – хезмәткәрләр), шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган һәм Министрлык эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм аңа хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы эшчеләр (алда – эшчеләр) тарафыннан кылынган коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау үзенчәлекләрен билгели. Башка затларга карата шундый ук фактлар турында белешмәләрне эченә алган мөрәҗәгать, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 ел 2 нче май № 59-ФЗ Федераль законның 8 нче статьясының 3 нче өлеше нигезендә компетенцияләренә мөрәҗәгатьләрдә куелган мәсьәләләрне хәл итү кергән, тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш.

2. Мөрәҗәгать «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлә һәм карала.

3. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге тарафыннан билгеләнгән тәртиптә хезмәткәргә (эшчегә) карата хезмәт тикшерүе башлана.

4. Хезмәт тикшерүен үткәргән Комиссия бәяләмәсе нигезендә коррупция чагылышы билгеләре булу турында мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар расланган очракта, министр йә аның вазыйфаларын башкаручы зат күрсәтелгән бәяләмәне алган көннән алып өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы ГТХМ дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу Комиссиясенә тәкъдим кертә. Хезмәткәргә (эшчегә) карата тиешле фактлар расланган очракта, аның язма аңлатмаларын анализлаудан чыгып, аңа Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану мәсьәләсе хәл ителә.

Хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча әзерләнә торган, кылына торган яисә кылынган законга каршы гамәлләр турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган кеше турында билгеле булган очракта, әлеге пунктның 1 абзацында күрсәтелгән вакыт эчендә тиешле мәгълүмат аларның компетенциясе нигезендә хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

5. Мөрәҗәгать җибәргән гражданинга җавап әзерләү Татарстан Республикасы ГТХМда коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан башкарыла.

6. Мөрәҗәгатьтә җаваплы затка карата коррупция юнәлешендәге фактлар турында белешмәләр булса, ул, үз үзен кире кагуны белдереп, аны карауда катнашмый. Мондый мөрәҗәгатьне карау Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән расланган комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.